Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы Карары

20 январь 2020 ел № 120

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге «Җир салымы турында " 105 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 31нче маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Югары Сәрдә авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Советының 2019 елның 3 октябрендәге 105 номерлы «Җир салымы турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

2.2. 0,12 процент Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары яки индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына керми торган җир кишәрлегеннән һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) ;

**1.2. 4.2 пунктта сүзтезмәне төшереп калдырырга** :

« яки шәхси эшмәкәрләр булган физик затлар»

**1.3. 5 пунктны төшереп калдырырга .**

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Хөснетдинов